| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.12.2023 Кошман ав. № 65

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 286-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман» муниципаль берәмлеге Уставына кушымтада каралганча үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина

Совет Кушманского сельского поселения Кошман авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлегенең
2023 е. 08 декабрендәге
65 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кошман» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

2. 30 статьяның 11 өлешендә, 40 статьяның 5 өлешендә, 42 статьяның 1 өлешендә, 43 статьяның 6 өлешенең 2 пунктындагы б пунктчасында, 45 статьяның 10 өлешенең 2 пунктындагы б пунктчасында, 79 статьяның 7 өлешендәге 4 абзацында слова «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

3. 30 статьяның 12 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

4. 30 статьяның 13 өлешен үз көчен югалткан дип санарга.

5. 49 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

6. 51 статьяда:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пунктының старостасы аның составына әлеге авыл торак пункты керә торган авыл торак пунктының гражданнар җыены тәкъдим итүе буенча җирлек советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пункты Старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары, йә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм әлеге торак пункт территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Авыл торак пункты Старостасы үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирлек Советы депутаты яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын башкаручы муниципаль вазыйфадан кала дәүләт вазыйфасы, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы, муниципаль вазыйфаны биләүче зат була алмый, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм алар белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә була алмый.»;

4 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасыннан тыш, дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче;».

7. 64 статьяда:

1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, затның үзе дә бер ягында булган яклар конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чараларын күрмәве;

1 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) затның, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында турында белешмәләр тапшырмавы, ачыктан-ачык тулы булмаган белешмәләр тапшыруы йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыруы;

2 өлештә «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.